ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2022 г. Казань № 754-31/т-2022

Чаллы шәһәренең «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә 2023 елга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 16 декабрендәге 44-ПР номерлы идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чаллы шәһәренең «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә, әлеге карар кушымтасына туры китереп, чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь дәрәҗәдә чик тарифлар 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Чаллы шәһәренең «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү турында» 16.03.2022 № 17-1/т-2022 карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2022 № 754-31/т-2022
карарына кушымта

Чаллы шәһәренең «Железнодорожник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдалануда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар

I бүлек. Чик дәрәҗәдә максималь тариф

| т/с | Хезмәт төре | Чик дәрәҗәдә максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|
| 1. | Чаллы маневр районы буенча 1 км ераклыкка 1 тонна йөк ташу | 26,71 |
| 2. | Круглое Поле маневр районы буенча 1 км ераклыкка 1 тонна йөк ташу | 18,42 |
| 3. | Сидоровка маневр районы буенча 1 км ераклыкка 1 тонна йөк ташу | 9,31 |
| 4. | Автозавод маневр районы буенча 1 км ераклыкка 1 тонна йөк ташу | 10,64 |

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган, әмма «Чик дәрәҗәдә максималь тариф» дигән I бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар яклар килешүендә, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

3. Йөк ташу буенча түләү алу өчен ераклык төгәл санга түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге